РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«2» июля 2019 ел г. Альметьевск № 1204

Әлмәт башкарма комитетының
2013 ел 27 июнендәге№ 2663
«Административ хокук бозулар
буенча беркетмәләр төзергә вәкаләтле
вазифаи затлар исемлеге турында»гы
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарын административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазифаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Кодексына һәм Татарстан Республикасы Законының 1 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 ел 7 ноябрендәге №87 ТРЗ Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2013 ел 27 июнендәге № 2663 «Административ хокук бозулар буенча беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазифаи затлар исемлеге турында»гы карарына (Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2013 ел 13 сентябрендәге №3438, 2013 ел 24 декабрендәге №4605, 2014 елның 17 июлендәге №2051, 2015 елның 9 апрелендәге №420, 2015 ел 14 июлендәге №751, 2015 ел 7 сентябрендәге №963, 2015 ел 9 ноябрендәге №1292, 2016 елның 10 июне № 1233, 2017 елның 21 марты № 429, 2018 ел 21 февралендәге №259, 2018 елның 23 маендагы №697 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 27 абзац өстәргә:

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 2.15 маддәсе 2 өлешендә каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазифаи затлар:

- Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының иҗтимагый һәм дини берләшмәләр белән үзара эшчәнлек секторы мөдире.».

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга,

Зак. № 3063

Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Район башкарма комитеты җитәкчесе вазифаларын башкаручы — Т.Д. Нагуманов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ